## Тырышалар



Савучының уңганлыгы хезмәт нәтиҗәләрендә күренә. Суфия Садретдинова бу яктан сыната торганнардан түгел, 20 елга якын фермада эшләү тәҗрибәсе булудан тыш, бу кешедәге күп кенә матур сыйфатлар да аңа уңыш гарантияләүче фактор булып тора. Терлекчелеккә ул үзе теләп килде. Үзен эштә күрсәтергә теләге зур иде. Һәм аңа ирешгте дә ул.

Савучы малларның характерын, мөмкинлеген аңлап, истә тотып эшли. Суфия апа яшьтән үк хезмәтне күңелне шатландырырлык итеп башкарырга күнеккән. Хезмәт күрсәткечләре буенча ул колхозда беренчелекне күп тапкырлар яулап, кыйммәтле бүләкләргә лаек булды. Агымдагы елның 9 аенда Суфия апа Садретдинова кулдашы Гөлфирә Хәлиуллина белән бергә һәр сыердан 1700 килограмм сөт савып алдылар. Хәзер фермаларда иң җаваплы этап —терлекләрне кышлату чоры башланды. Алар бу чорны да бергәләшеп өзеклекләргә юл куймаска тырышачаклар.

РӘСЕМДӘ: «Игенче» колхозы сыер савучылары Суфия Садретдинова һәм Гөлфирә Хәлиуллина.

## ТЕЛӘСӘЛӘР— БУЛДЫРАЛАР ИКӘН...

Норлат азык комбинатында әзерләнгән колбасаның сыйфаты турында әледән-әле сүз булып тора. Бәясе көннән-көн артып торса да сыйфаты һич кенә дә яхшырмый аның. Комбинат аңа сылтавын да таба: әле ит сыйфаты начар, әле компонентлар табуы читен, әле сәүдә нокталарында озак ятып сыйфатсыз хәлгә килә, диләр. Без инде алар яхшы сыйфатлы продукция чыгара алмыйлар дигән фикер белән килешергә дә җыенган идек.. Тик очраклы рәвештә комбинат район игенчеләренең уңыш бәйрәменә күргәзмәгә әзерләгән продукцияне күргәч, бөтенләй башка фикергә килдек: юк, безнең комбинатта колбасаны әзерли беләләр, бер дигән итеп әзерлиләр икән! Биредә колбасаның нинди генә сорты юк, ә сыйфаты тагын—тыгыз, хуш ис аңкып үзенә тартып тора. Кибетләрдә без гомердә мондый колбасаны күргәнебез юк.

Димәк, комбинат теләгәндә продукцияне сыйфатлы итеп әзерли ала. Нигә дип теләге җитеп бетми икән?

# ӨЛЕШЕҢӘ ТИГӘН КӨМЕШЕҢ

**Республика матбугатында «Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең 1992 елгы чыгарылыш хосусыйлаштыру чеклары системасын гамәлгә кертү турында» Татарстан Республикасы Президенты Указы басылып чыкты. Шунда ук Президент Указы белән раслангаң Положениеләр дөнья күрде. Указга 26 сентябрьдә кул куелган. Димәк, ул шул көннән гамәлдә.**

**Моның нәрсә икәнен, ничек тормышка ашырылачагын, дәүләткә һәм аерым кешеләргә нинди файда китерәчәген, кыскача гына әйткәндә, төп максатын аңлатуны сорап хатлар килә башлады, телефоннан сорыйлар, үзара сөйләшүләрдә аптырап җилкә җыералар. Шуларны искә алып безнең хәбәрчебез Татарстан Республикасы Дәүләт мөлкәтен идарә итү дәүләт комитетының икътисад идарәсе начальнигы Р. ХӨСНЕТДИНОВка мөрәҗәгать итте.**

—**Рәис Әгъзамович, бик күпләрне әлегә нык аптырашта калдырган бу яңалыкның асылы нидән гыйбарәт?**

—Президент Указын игътибар белән укыган һәр кеше моны аңлар сыман. Анда максат ачык итеп күрсәтелгән: Республика гражданнарына дәүләт милкен бирүне тизләтү, халыкларның киң катлауларын хосусыйлаштыру процессына тарту, Россия Федерациясенең бердәм икътисадый киңлеген саклау.

—**Татарстан суверен дәүләт дип игълан ителде. Хосусыйлаштыру чеклары таратуның да үзебезгә генә хас яклары бармы?**

—Ни генә теләсәк тә, без моннан читтә кала алмыйбыз. Бердәм, икътисадый киңлек саклана. Шулай да аерымлыклар бар. Бу— табигый. Мәсәлән, бездә хосусыйлаштыру чеклары аукционнарда коммуналь милекне сатып алганда, шулай ук торакны хосусыйлаштырганда да файдаланыла ала. Безнең комитет җир сатып алучыларга да чеклар куллануны күз алдында тота. Дөрес, Югары Совет моңа ничек карар? Монысы алдарак хәл ителер. Ваучерлаштыру дәүләтнең бар мөлкәтен өләшеп бетерү дигән сүз түгел. Моңа аның якынча өчтән бер өлеше генә китә.

—**Кем уйлап тапкан шул ваучер дигән сүзне? Әйтә башласаң, тел көрмәкләнә.. Ул нинди мәгънәдә соң?**

—Россия Президенты Указында да, безнекендә дә бу сүз юк. Аны халык үзе уйлап чыгарган. Дөресрәге, минемчә, аны сез, журналистлар тараттыгыз бит. Ваучер дәүләт байлыгын өләшүне аңлатадыр, шәт. Халыкта канатлы сүз бар бит, «өлешеңә тигән көмешең»,— диләр.

—**Бу очракта өлеш кәгазенең бәясе 10 мең сум. Бу—иске бәяләрдә. Әмма ул кәгазьдән, ягъни чектан ботка пешереп булмый бит.**

—Ваучерны файдалануның әлегә өч мөмкинлеге бар. **Кайсы да булса предприятиенең акцияләрен алырга; чекны акчага сатарга; инвестиция фонды акцияләренә алыштырырга.**

—**Беренче ике мөмкинлек, Рәис Әгъзамович, аңлашыла төсле. Ә менә өченчесе..**

—Президентыбыз Указы белән расланган Положениенең 4 нче статьясының 2 нче пунктында ике төрле инвестиция булуы турында әйтелгән: Милли инвестиция фонды һәм махсус инвестиция фонды. Беренчесе, коммерция нигезендә эшли. Ул дәүләт карамагында калган предприятиеләр акцияләре белән ныгытыла. Милли фонд халыкның социаль яклауга мохтаҗ булган катламнары мәнфәгатен күз алдында тота. Махсус инвестиция фонды исә инициатива группаларын оештыра. Ул акционерлык җәмгыяте формасында эшләр. Үзара конкуренция булуы мөмкин. Бу фондка икътисадый яктан компетентлы хуҗалыкчыл кеше җитәкчелек итә.

—**Рәис Әгъзамович, безгә, гади ваучерчыларга, Сез әйткән өч мөмкинлектән кайсын сайлап алырга икән? Аптырашта калуың бар бит. Татарча әйтсәк, төп башына утырып калмагаек.**

—Бик мөмкин. Андый куркыныч бар. Ләкин аннан яклау чаралары да күрелә. Иң әүвәл кулыңа чек тоту белән аны тизрәк файдаланырга ашыгырга кирәкми. Акцияләр сатып алырга җыенасың икән, андый предприятиеләрнең күп булуын көтү мәслихәтрәк. Ни дисәң дә, сайларга була. Шул максаттан Татарстан Республикасы Президентының махсус Указы бар. Ул «Дәүләт берләшмәләрен, предприятие һәм оешмаларны акционерлык җәмгыятьләре итеп үзгәртеп кору турында». Указда «бу эшне 1993 елның 1 гыйнварына төгәлләргә» диелгән.

Димәк, кайсы предприятиегә ышанычың зур, кайсысының акциясе сиңа күбрәк файда китерер дип уйлыйсың, ул рәсми телдә «дивиденд» дип йөртелә, гади генә әйтсәк, кайсысы сине кәкре каенга терәтеп калдырмас, шунысын сайлау турында ныклап уйланырга кирәк.

Чекны акчага әйләндерергә дә ашыкмаска киңәш итәр идем. Аны арзан бәягә сатып алырга теләүчеләр табылыр, ләкин тора-бара ваучерның бәясе, хәзерге бәяләрдән чыгып, кыйбатланырга, 10 мең сум урынына 200 мең сумга җитәргә мөмкин.

—**Шулай да иң ышанычлы мөмкинлек кайсысы?**

—Милли инвестиция фонды акцияләре, дияр идем. Чөнки монда табыш алу гарантиясе зур. Бөлгенлеккә чыгу куркынычы азрак, шуңа күрә, башта әйткәнемчә, халыкның социаль яклауга мохтаҗ катламы—ялгыз карт-карчыклар, гарипләр, авырулар иң беренче чиратта шушы фондка мөрәҗәгать итсеннәр иде. Ышанычлы да, файдалы да.

—**Хәзер инде практик ягына килик. Хосусыйлаштыру чекларын бездә кайчан бирә башлыйлар.**

—Быелның 1 ноябреннән, Россия Федерациясендә 1 октябрьдән башлау каралган. Аларда инде 1 нче декабрьдән ваучерларны реализацияләүгә тотыналар. Ә бездә —1 гыйнвардан. Бер ай эчендә күп нәрсә ачыкланачак.

—**Россия даирәләре бердәм икътисадый киңлекне бозасыз дип дәгъва белдермәсләрме?**

—Юк, без аны бозмыйбыз, үзебезгә яраклаштырабыз гына. Россиянең теләсә кайсы төбәгендә алынган чекны һәркайда, шулай ук Татарстанда да бернинди каршылыксыз акцияләргә алыштырырга, өч мөмкинлекнең теләсә кайсын сайларга була. Бездә өләшенгән чеклар да Россия Федерациясенең теләсә кайсы төбәгендә гамәлдә санала. Түмәнгә барасыңмы, Ерак Көнчыгышкамы, рәхим ит, синең үз иркеңдә.

—**Чекны каян алырга? Аның өчен нәрсә кирәк?**

—Саклык банкыннан аласы. Исемлекне йорт идарәләре, торак файдалану участоклары, авылларда авыл Советлары төзеп, аны махсус комиссиягә тапшыра. Шунда расланган исемлек саклык банкына бирелә. Чек алу өчен паспорт кирәк. Алганда 25 сум комиссион җыем түлисең. Әгәр дә кем дә булса чек алырга үзе килә алмый икән, аны карауга алынган кеше (опекун, попечитель) үзенең вәкаләтен раслый торган документ күрсәтә. Балалар паспортта язылган булырга тиеш, аларның туу турындагы таныклыкларын да үзең белән алырга кирәк.

—**Чекларны банкта акчага әйләндереп булмыймы?**

—Юк, булмый. Гомумән, хосусыйлаштыру чекларын кулланып, кайберәүләр уйлаганча бик тиз генә баеп китәргә исәп тоту, җиңелчә генә әйткәндә, беркатлылык булыр иде. Ваучер тоткан кешегә һәрхәлдә күк капусы ачылмас. Шулай да халыкның тормыш хәлен җиңеләйтүдә моның күпмедер күләмдә йогынтысы булыр. Базар мөнәсәбәтләренә күчә баруның бер баскычы бит бу. Президентыбыз Указында әйтелгәнчә, халыкның киң катлаулары хосусыйлаштыру процессына тартылачак. Россия Федерациясендә 150 миллионнан артык чек өләшенә икән, халык берләшмәләрне, предприятие һәм оешмаларны тизрәк хосусыйлаштыруны таләп итәчәк. Чөнки ваучерның гамәлдә булу срогы бер генә ел итеп билгеләнә.

—**Рәис Әгъзамович, безнең газетаны укучыларның күбесе авылда. Билгеле инде, без ул чеклар белән нишләрбез, дигән сорауга җавап бирүегезне түземсезлек белән көтеп торалардыр.**

—Иң башта төгәл исемлек кирәк. Беркем дә «онытылып» калырга тиеш түгел. Минемчә болай. Авылдагы һәр гаиләнең шәһәрдә кеме булса да бар. Туган-тумачалары, диюем. Шулар аша акцияләр юнәтергә мөмкин. Ә картлар-карчыклар һәм башкалар өчен иң җайлысы Милли инвестиция фонды акцияләрен алу. Иң ышанычлы юл шушы. Тагын бер тапкыр кисәтеп әйтәм, чекларны авыллар буйлап арзан хакка җыеп йөрүчеләр булачак. Хәзер үк кулыма акча керә дип ымсынырга кирәкми. Алданмагыз, ашыкмагыз. Андый кәсеп белән йөрүчеләргә капкаларыгыз ябык, ишекләрегез бикле булсын.

—**Шулай да, Рәис Әгъзамович, кем булса да берәү, аның чит өлкәдән булуы да мөмкин, кулына бик күп чек тотып, акция сатып алырга килде, ди.**

—Бу очракта әгәр дә аның чеклары номиналь бәядән 20 тапкыр артып китсә, ягъни 200 мең сумнан, ул кеше чекларны каян алу турында декларация күрсәтергә тиеш. Бу Положениедә каралган: 4 нче статьяның 2 нче пунктын укыгыз.

Җае туры килгәндә әйтим әле. Президент Указы белән расланган Положениенең татарча тәрҗемәсендә шактый төгәлсезлекләр бар, укырга да, аңларга да авыр. Мәсәлән, «Хосусыйлаштыру чегына акча түләнә һәм ул әйләнештән чыгарыла» (1 нче статьяның 2 пунктындагы соңгы абзац). Монда мәгънә бозылган. Яки «яшерен подписка турындагы положение», «Хосусыйлаштыру объектының кыйммәте тулысынча яки өлешчә хосусыйлаштыру чеклары белән түләнә ала», «Хезмәт коллективларына сату бәясе 35 проценттан артмаган суммада сатылырга мөмкин» (1 статьяның 1 нче пункты), «Гамәлдә булган хосусыйлаштыру чекларын туплый торган махсус инвестиция фондларын тиешле положениеләр нигезендә сатып алырга мөмкин» (4 нче статьяның 2 нче пункты) һәм башкалар. Бу җөмләләрнең тәрҗемәләре шактый камилләштерүне сорый.

—**Тел турында Закон кабул ителсә дә, Рәис Әгъзамович, әле һаман безгә Указлар, карарлар рәсми документлар урыс телендә килә. Һәр газетаның үз тәрҗемәчеләре бар. Һәркайсы үзенчә тәрҗемә итә. Президент аппаратыннан, Югары Советтан, Министрлар Кабинетыннан камил тәрҗемә ителгән бердәм текст килсә, мондый чатаклыклар килеп чыкмас иде. Сезнең тәнкыйтьнең үзебезгә кагылган өлешен кабул итәбез.**

**Әңгәмәгез өчен рәхмәт.**

**Әңгәмәне газета хәбәрчесе М. ХӨСНИМӘРДӘНОВ алып барды.**

**(«Ватаным Татарстан» газетасыннан).**

